**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2024 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

2024 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен һәм «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты» исемен түбәндәгеләргә бирергә:

1. «Төрки-татар дөньясының этногенезы һәм этномәдәни мирасы буенча комплекслы тикшеренүләр тәҗрибәсе» хезмәтләр циклы өчен – Бакиров Марсель Хәернас улына, филология фәннәре докторы, профессор, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Лев Толстой мирасын өйрәнү буенча фәнни-белем бирү үзәге әйдәүче фәнни хезмәткәренә.

2. «Йогышлы авыруларны дәвалау һәм алардан соң өзлегүләрне кисәтүдә яңа патогенетик юнәлеш булдыру» хезмәте өчен:

Патяшина Марина Александровнага, медицина фәннәре докторы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе мөхбир-әгъзасы, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе, Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт санитария табибына, хезмәтнең җитәкчесенә;

Анохин Владимир Алексеевичка, медицина фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең балалардагы йогышлы авырулар кафедрасы мөдиренә;

Жданов Ренат Ибраһим улына, химия фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Үзәк фәнни-тикшеренү лабораториясе баш фәнни хезмәткәренә;

Киясов Андрей Павловичка, медицина фәннәре докторы, профессор, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе мөхбир-әгъзасы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Фундаменталь медицина һәм биология институты директорына;

Хәсәнова Гөлшат Рашат кызына, медицина фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең эпидемиология һәм дәлилле медицина кафедрасы мөдиренә;

Яковлев Михаил Юрьевичка, медицина фәннәре докторы, «Гомуми патология һәм патофизиология фәнни-тикшеренү институты» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең системалы эндотоксинемия һәм шок лабораториясе мөдиренә (Мәскәү шәһәре).

3. «Россия Федерациясенең медицина, биология һәм дарулар белән бәйләнешле рәвештә куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында комплекслы фәнни-техник карарлар эшләү һәм аларны махсус медицина җиһазларын массакүләм җитештерүдә куллануга кертү» хезмәте өчен:

Драгунских Игорь Викторовичка, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директорының техник үсеш буенча урынбасары – җәмгыятьнең баш инженерына, хезмәтнең җитәкчесенә;

Мифтахов Ирек Шамил улына, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте баш конструкторы – инновация-техник үзәк башлыгына;

Тураев Рамил Габделхак улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибына;

Фәхретдинов Тимур Илгизәр улына, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең маркетинг һәм сату эшләре департаменты башлыгына;

Хәсәнов Булат Радик улына, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директорының стратегик маркетинг буенча урынбасарына.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 30 ноябрь
№ 925